Глава
Большеаксинского сельского
поселения Дрожжановского
муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Аксу авыл җирлеге
Башлыгы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 12 октябре №18

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы стандартына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында», 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» федераль законнар, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында кодексы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 20 октябрендәге 13 номерлы карары(2018 елның 5 июнендәге 12 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы үз-үзен тотышы стандартына түбәндәге үзгәрешне кертергә:
4 пунктның 4.2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашу Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә рөхсәт ителә;
муниципаль берәмлек катнашкан оешманың идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләрне (устав капиталында катнашу өлешләре) гамәлгә куючы яисә аның белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар һәм федераль законнарда каралган башка очракларда түләүсез бирү рөхсәт ителә;".
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы: А.В.Храмов